ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 571-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 571-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2024 елның 6 июне
№ 2480-VI ДС

проект

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинеты
тарафыннан кетрелә

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗАКОНЫ

**Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында**

**1 статья**

«Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законының 45 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 1; 2005, № 10 (II өлеш); 2006, № 12 (I өлеш); 2007, № 11; 2008, № 3, № 10 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2009, № 12 (I өлеш); 2010, № 1 – 2, № 10 (II өлеш); 2011, № 5, № 11 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш); 2013, № 2 (I өлеш), № 3, № 11 (I өлеш); 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш); 2016, № 4, № 7 – 8, № 9 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнары җыентыгы, 2017, № 1 (I өлеш), № 85 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 54 (I өлеш), № 78 (I өлеш); 2020, № 4 (I өлеш), № 37 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 57 (I өлеш), 2022, № 34 (I өлеш), № 96 (I өлеш), 2023, № 27 (I өлеш), № 35 (I өлеш), № 48 (I өлеш), № 73 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2024, № 18 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Тиешле еллар эшләгән өчен пенсияне тиешле елда билгеләү өчен кирәкле дәвамлылыгы әлеге Законга кушымта нигезендә билгеләнә торган дәүләт хезмәте стажы булганда, дәүләт хезмәткәрләренә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары реестрында бер теркәлү номеры булган дәүләт хезмәтендә тиешле еллар эшләгән өчен пенсия анда эшләү вакыты 5 елдан да ким булмаган дәүләт хезмәткәренең айлык акчалата тулы керменең 35 проценты күләмендә билгеләнә. Шул ук вакытта тиешле еллар эшләгән өчен пенсия күләмен исәпләү өчен дәүләт хезмәтенең әлеге вазифасы буенча әлеге Закон нигезендә тиешле еллар эшләгән өчен пенсия билгеләнгән көнгә билгеләнә торган айлык акчалата түләү күләме кулланыла.

Дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләгән кешенең берничә дәүләт хезмәте вазыйфасы буенча 5 елдан да ким булмаган стажы булганда, пенсиягә өстәмә түләү аның дәүләт хезмәте вазыйфасын сайлавы буенча билгеләнә.

Дәүләт хезмәте стажының тиешле еллар эшләгән өчен пенсия билгеләү өчен кирәкле күрсәтелгәннән артып киткән һәр тулы елы өчен тиешле еллар эшләгән өчен пенсия дәүләт хезмәте вазыйфасы буенча әлеге өлешнең беренче абзацына ярашлы рәвештә билгеләнә торган айлык акчалата тулы керемнең 3 процентына арта. Шул ук вакытта тиешле еллар эшләгән өчен пенсия күләме пенсия билгеләнгән көнгә эшләү вакыты 5 елдан да ким булмаган дәүләт хезмәткәренең тиешле еллар эшләгән өчен дәүләт хезмәте вазыйфасы буенча айлык акчалата тулы кеременең 80 процентыннан артыграк була алмый.

Бер вазыйфада 5 елдан да ким булмаган дәүләт хезмәте стажы булмаган очракта, тиешле еллар эшләгән өчен пенсия «Иминият пенсияләре турында» Федераль законның 16 статьясының 1 өлеше нигезендә билгеләнгән картлык буенча иминият пенсиясенә фиксацияләнгән түләүгә тиң күләмдә билгеләнә.»;

2) 5 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Бетерелгән һәм (яки) Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары реестры нигезендә теркәлү номеры булмаган дәүләт хезмәте вазыйфаларының һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары реестрында күрсәтелгән вазыйфаларның нисбәте Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән тәртиптә билгеләнә.»;

3) 9 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9. Тиешле еллар эшләгән өчен пенсия билгеләү, аларның күләмнәрен яңадан исәпләп чыгару һәм аларны түләү, аларны китереп тапшыруны оештыруны да кертеп, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләт тапшырган орган тарафыннан башкарыла. Тиешле еллар эшләгән өчен пенсия түләү акчаны Россия Федерациясе территориясендәге кредит оешмаларындагы шәхси счетларга күчерү яки Татарстан Республикасы территориясендә даими яшәү урыны буенча почта элемтәсе оешмасы аша китереп бирү юлы белән башкарыла. Пенсияне алу ысулын гариза бирүче сайлый һәм ул тиешле еллар эшләгән өчен пенсия билгеләү турында гаризада күрсәтелә.»;

4) 12 өлешнең беренче абзацында «әлеге статьяның 4 өлеше кагыйдәләре буенча исәпләнгән» сүзләрен төшереп калдырырга.

**2 статья**

«Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфалары турында» 2006 елның 4 мартындагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 3 (I өлеш); 2007, № 7 (II өлеш); 2008, № 7 (II өлеш), № 12 (I өлеш); 2009, № 12 (II өлеш); 2010, № 1 – 2, № 4 (I өлеш); 2011, № 5; 2012, № 7 (I өлеш); 2013, № 2 (I өлеш), № 3, № 11 (I өлеш); 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 11 (I өлеш); 2016, № 4, № 6 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнары җыентыгы, 2017, № 52 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш); 2020, № 37 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 57 (I өлеш); 2022, № 83 (I өлеш); 2023, № 27 (I

өлеш), № 35 (I өлеш), № 73 (I өлеш), № 92 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 13 статьяның 1 өлешендә:

а) беренче абзацта «, эш стажына (хезмәтенә) карамастан» сүзләрен «шул вазыйфада кимендә тулы бер срок узгач, ә инвалидлык буенча пенсия билгеләнгәндә, вәкаләтләр үтәү срогына бәйсез рәвештә» сүзләренә алмаштырырга;

б) түбәндәге эчтәлектәге абзацны өстәргә:

«Татарстан Республикасы югары вазыйфаи заты үз вәкаләтләрен бер сроктан артык башкарган очракта, гомер буе ай саен акча алу хокукы Татарстан Республикасы Рәисенең айлык акчалата тулы кеременең 100 проценты күләмендә билгеләнә»;

2) 13[1] статьяның 1 өлешендә:

а) беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы рәисе вазыйфасында тулы бер сроктан да ким булмаган вакыт узгач вәкаләтләрен башкаруны туктаткан затка, Татарстан Республикасы Премьер-министрына әлеге вазыйфада 5 елдан да ким булмаган вакыт булу шарты белән, ә инвалидлык буенча пенсия билгеләнгәндә, вәкаләтләр үтәү срогына бәйсез рәвештә:

б) 1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) пенсиягә, Татарстан Республикасының тиешле дәүләт вазыйфасы буенча айлык акчалата тулы кеременең 80 проценты күләмендә өстәмә билгеләнә. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе үз вәкаләтләрен бер сроктан артык башкарган, Татарстан Республикасы Премьер-министры вазыйфасында 5 елдан артык булган очракта гомер буе ай саен акчалата түләү Татарстан Республикасының тиешле дәүләт вазыйфасы буенча исәпләнгән айлык акчалата бүләкләүнең 100 проценты күләмендә билгеләнә.»;

3) 15 статьяда:

а) 1 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Әлеге Закон нигезендә пенсиягә өстәмә алу хокукына дәвамлылыгы Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнгән Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын вәкаләтләрне үтәүнең тулы бер срогыннан да ким булмаган вакытта даими нигездә биләгән затлар ия, әгәр бу статьяда башкасы каралмаган булса.

Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе җитәкчесе, Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары дәүләт вазыйфаларын биләгән затлар әлеге вазыйфада кимендә 5 ел булганда һәм дәүләт хезмәтенең гомуми стажы 15 елдан ким булмаганда әлеге Закон нигезендә пенсиягә өстәмә түләү хокукына ия, әгәр бу статьяда башкасы каралмаган булса.

Татарстан Республикасы министры, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең башка органы җитәкчесе – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты әгъзасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар әлеге Закон нигезендә пенсиягә өстәмә түләү хокукына, әлеге вазыйфада кимендә 5 ел булганда һәм дәүләт

хезмәтенең гомуми стажы 20 елдан ким булмаганда ия булалар, әгәр бу статьяда башкасы каралмаган булса.

Татарстан Республикасы Хисап палатасы аудиторы әлеге Закон нигезендә, әлеге вазифада ким дигәндә 6 ел булганда һәм дәүләт хезмәтенең гомуми стажы 20 елдан ким булмаганда ия була, әгәр бу статьяда башкасы каралмаган булса»;

б) түбәндәге эчтәлектәге $1^1$ өлешне өстәргә:

«$1^1$. Пенсиягә өстәмә түләү әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләгән затларга алар вәкаләтләрен туктаткан очракта (шул исәптән вакытыннан алда) түбәндәге очракларда билгеләнми:

1) вазыйфасыннан азат итү;

2) ышанычны югалту (ышанычсызлык белдерү);

3) судның гаепләү карарының законлы көченә керүе;

4) сайлаучылар тарафыннан кире чакырылу;

5) чикләүләрне һәм тыюларны үтәмәү, федераль законнарда билгеләнгән йөкләмәләрне үтәмәү;

6) дәүләт вазыйфасын биләүгә комачаулаучы шартлар ачыклану;

7) дәүләт вазыйфасын биләү белән бәйле вәкаләтләрне үтәмәү яки тиешенчә үтәмәү;

8) сайлаулар һәм референдумнар турындагы законнарны бозган өчен һәм Админситратив хокук бозулар турында Россия Федерациясе Кодексының 20.3 һәм 20.29 статьяларында каралган административ хокук бозулар кылган өчен административ җәза билгеләү турында суд карарының законлы көченә керүе.»;

в) 2 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән затларга пенсиягә өстәмә түләү айлык акчалата тулы керемнең 70 проценты күләмендә билгеләнә. Шул ук вакытта пенсиягә өстәмә күләмен исәпләү өчен бу вәкаләтләрне үтәү (аларда булу) әлеге Закон нигезендә пенсиягә өстәмә түләү хокукы бирә торган Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасы буенча пенсиягә өстәмә билгеләнгән көнгә әлеге Закон нигезендә билгеләнгән айлык акчалата бүләкләү күләме кулланыла.

Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләгән кешенең берничә Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасы буенча 5 елдан да ким булмаган стажы (вазыйфада тулы бер срок) булганда, пенсиягә өстәмә түләү аның Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын сайлавы буенча билгеләнә.

Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләгән затларга, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитеты рәисе һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советында һөнәри даими нигездә эшләү өчен сайланган һәм әлеге статьяның 1 өлеше нигезендә пенсиягә өстәмә түләү хокукына ия булган Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты вазыйфаларыннан тыш, пенсиягә өстәмә түләү Татарстан Республикасының әлеге дәүләт вазыйфасын яисә Татарстан Республикасының башка дәүләт вазыйфаларын пенсиягә өстәмә түләү билгеләү өчен кирәк булган сроктан тыш даими нигездә биләгән һәр ел өчен 3 процентка арта.

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитеты рәисе вазыйфасын биләгән һәм әлеге статьяның 1 өлеше нигезендә пенсиягә өстәмә түләү хокукына ия булган

затларга пенсиягә өстәмә түләү әлеге дәүләт вазыйфасын яисә Татарстан Республикасының башка дәүләт вазыйфаларын пенсиягә өстәмә түләү билгеләү өчен кирәк булган сроктан тыш даими нигездә биләгән һәр ел өчен 2 процентка арта.

Татарстан Республикасы Дәүләт Советында һөнәри даими нигездә эшләү өчен сайланган һәм әлеге статьяның 1 өлеше нигезендә пенсиягә өстәмә түләү хокукына ия булган Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты булган затларга пенсиягә өстәмә түләү әлеге дәүләт вазыйфасын яисә Татарстан Республикасының башка дәүләт вазыйфаларын пенсиягә өстәмә түләү билгеләү өчен кирәк булган сроктан тыш даими нигездә биләгән һәр ел өчен 1 процентка арта.».

**3 статья**

«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында» 2009 елның 12 февралендәге 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 2; 2010, № 1 – 2; 2011, № 5; 2012, № 12 (II өлеш); 2014, № 6 (II өлеш), № 12 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнары җыентыгы, 2018, № 1 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш); 2020, № 26 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 77 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш), 2023, № 92 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 өлештә:

а) бишенче һәм алтынчы абзацларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«РК – муниципаль район һәм шәһәр округы башлыгы, башлык урынбасары вазыйфаларын биләгән затлар өчен билгеләнгән исәп-хисап коэффициенты – 1,5, җирле үзидарә органнарында башка муниципаль вазыйфаларны биләгән затлар өчен – 1;

КС – стаж коэффициенты, ул муниципаль вазыйфаларны биш елдан ким булмаган срокта йә җирле үзидарә органы вәкаләтләрен тулы бер срок, әмма кимендә өч ел биләгәндә 0,7 гә тиң. Муниципаль вазыйфаны 5 елдан артык биләүнең һәр тулы елы өчен йә җирле үзидарә органы вәкаләтләрен тулы бер срок, әмма кимендә өч ел биләгәндә пенсиягә өстәмә түләү айлык акчалата бүләкләүнең 3 процентына арта.»;

б) түбәндәге эчтәлектәге абзацны өстәргә:

«Муниципаль вазыйфаларны биләгән кешенең берничә муниципаль вазыйфа буенча 5 елдан да ким булмаган стажы (вазыйфада тулы бер срок) булганда, пенсиягә өстәмә түләү аның муниципаль вазыйфаны сайлавы буенча билгеләнә.»;

2) 3 өлешнең 1 һәм 2 пунктларында «дәүләт» сүзен төшереп калдырырга;

3) 5 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Татарстан Республикасы министрының пенсиясенә өстәмә күләме әлеге статьяның 3 өлеше максатларында түбәндәге тәртиптә билгеләнә:

1) муниципаль вазыйфаны биш елдан ким булмаган йә җирле үзидарә органы вәкаләтләрен тулы бер срок, әмма кимендә өч ел биләгән затларга карата – дәүләт вазыйфасын кимендә биш ел биләгән һәм дәүләт хезмәтенең гомуми стажы 20 елдан ким булмаган Татарстан Республикасы министрының дәүләт пенсиясенә өстәмә күләме буенча;

2) муниципаль вазыйфаны 5 елдан артык биләгән йә җирле үзидарә органы вазыйфасын тулы бер срок, әмма кимендә өч ел биләгән затка карата – министрның пенсиясенә әлеге статьяның 5 өлешендәге 1 пункты нигезендә билгеләнгән өстәмә түләү күләме муниципаль вазыйфаны 5 елдан артык биләгәннән яки җирле үзидарә органы вәкаләтләрен тулы бер срок, әмма кимендә өч ел биләгәннән соңгы һәр ел өчен 3 процентка арта.

Шул ук вакытта министр пенсиясенә өстәмә түләү күләме пенсиягә өстәмә түләү билгеләнгән көнгә исәпләнгән айлык акчалата бүләкләүнең 100 процентыннан артык булырга тиеш түгел.»;

4) 6 өлештә «дәүләт» сүзен төшереп калдырырга;

5) 8 өлешне үз көчен югалткан дип танырга.

**4 статья**

Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 6 (II өлеш); 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 12 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш); 2016, № 4, № 7 - 8, № 9 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнары җыентыгы, 2017, № 1 (I өлеш), № 17 (I өлеш), № 52 (I өлеш), № 55 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 54 (I өлеш), № 78 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 19 (I өлеш), № 49 (I өлеш); 2020, № 4 (I өлеш), № 37 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 57 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш), № 24 (I өлеш); 2023, № 11 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 73 (I өлеш), № 81 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2024, № 18 (I өлеш), № 34 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 28 статьяда:

а) 4 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Муниципаль хезмәткәрләргә тиешле еллар эшләгән өчен пенсия тиешле еллар эшләгән өчен пенсия билгеләү өчен дәвамлылыгы җитә торган муниципаль хезмәт стажы булганда әлеге Кодекска кушымта нигезендә Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт вазыйфалары реестрында бер теркәлү номеры булган муниципаль хезмәт вазыйфасы буенча вазыйфаны кимендә 5 ел биләгән муниципаль хезмәткәргә айлык акчалата түләүнең 35 проценты күләмендә билгеләнә.

Шул ук вакытта тиешле еллар эшләгән өчен пенсия күләмен исәпләү өчен муниципаль хезмәтнең әлеге вазифасы буенча тиешле еллар эшләгән өчен пенсия билгеләнгән көнгә әлеге Закон нигезендә билгеләнгән айлык акчалата түләү күләме кулланыла.

Муниципаль вазыйфаларны биләгән кешенең берничә муниципаль вазыйфа буенча 5 елдан да ким булмаган стажы булганда пенсиягә өстәмә түләү аның сайлавы буенча билгеләнә.

Муниципаль хезмәт стажының тиешле еллар эшләгән өчен пенсия билгеләү өчен кирәкле күрсәтелгәннән артып киткән һәр тулы елы өчен тиешле еллар эшләгән өчен пенсия муниципаль хезмәт вазыйфасы буенча әлеге өлешнең беренче абзацына ярашлы рәвештә билгеләнә торган айлык акчалата тулы керемнең 3 процентына арта. Шул ук вакытта тиешле еллар эшләгән өчен пенсия күләме пенсия билгеләнгән көнгә эшләү вакыты 5 елдан да ким булмаган муниципаль хезмәткәрнең тиешле еллар эшләгән өчен муниципаль хезмәт вазыйфасы буенча айлык акчалата тулы кеременең 80 процентыннан артыграк була алмый.

Муниципаль хезмәтнең бер вазыйфасында 5 елдан да ким булмаган хезмәт стажы булмаган очракта, тиешле еллар эшләгән өчен пенсия «Иминият пенсияләре турында» Федераль законның 16 статьясының 1 өлеше нигезендә билгеләнгән картлык буенча иминият пенсиясенә фиксацияләнгән түләүгә тиң күләмдә билгеләнә.»;

б) 7 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Бетерелгән һәм (яки) Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт вазыйфалары реестрына ярашлы рәвештә теркәлү номеры булмаган муниципаль хезмәт вазыйфаларының һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары реестырнда күрсәтелгән вазыйфаларның нисбәте Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларының нисбәтен билгеләү өчен каралган тәртиптә билгеләнә.»;

в) 16 өлешнең беренче абзацында «әлеге статьяның 4 өлеше кагыйдәләре буенча саналган» сүзләрен төшереп калдырырга;

2) 1 кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль хезмәт турында
Татарстан Республикасы кодексына
1 нче кушымта

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА
МУНИЦИПАЛЬ ХЕЗМӘТ ВАЗЫЙФАЛАРЫ РЕЕСТРЫ

I кисәк

МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНДА
МУНИЦИПАЛЬ ХЕЗМӘТ ВАЗЫЙФАЛАРЫ

## 1 бүлек. ВӘКИЛЛЕКЛЕ ОРГАН АППАРАТЫНДАГЫ МУНИЦИПАЛЬ ХЕЗМӘТ ВАЗЫЙФАЛАРЫ

| Вазыйфаның исеме | вазыйфаның теркәү номеры <*> |
|---|---|
| **1. Муниципаль хезмәтнең югары вазыйфалары** | |
| Аппарат җитәкчесе (эшләр идарәчесе). | 01-1-01 |
| **2. Муниципаль хезмәтнең баш вазыйфалары** | |
| Мөстәкыйль бүлек башлыгы (мөдире). | 01-2-02 |
| **3. Муниципаль хезмәтнең әйдәп баручы вазыйфалары** | |
| Мөстәкыйль бүлек башлыгы (мөдире) урынбасары; | 01-3-03 |
| мөстәкыйль сектор урынбасары; | 01-3-04 |
| муниципаль район башлыгы ярдәмчесе; | 01-3-05 |
| муниципаль район башлыгы киңәшчесе; | 01-3-06 |
| мөстәкыйль бүлек составындагы сектор мөдире. | 01-3-07 |
| **4. Муниципаль хезмәтнең өлкән вазыйфалары** | |
| Бүлекнең, секторның баш белгече; | 01-4-08 |
| бүлекнең, секторның әйдәп баручы белгече. | 01-4-09 |
| **5. Муниципаль хезмәтнең кече вазыйфалары** | |
| Бүлекнең, секторның 1 категорияле белгече; | 01-5-10 |
| бүлекнең, секторның 2 категорияле белгече; | 01-5-11 |
| бүлек, сектор белгече. | 01-5-12 |

## 2 бүлек. БАШКАРМА КОМИТЕТТАГЫ, БАШКАРМА КОМИТЕТ АППАРАТЫНДАГЫ МУНИЦИПАЛЬ ХЕЗМӘТ ВАЗЫЙФАЛАРЫ

| | |
|---|---|
| **1. Муниципаль хезмәтнең югары вазыйфалары** | |
| Башкарма комитет җитәкчесе; | 01-1-13 |
| башкарма комитет җитәкчесенең беренче урынбасары; | 01-1-14 |
| башкарма комитет җитәкчесе урынбасары; | 01-1-15 |
| башкарма комитет аппараты җитәкчесе (эшләр идарәчесе). | 01-1-16 |
| **2. Муниципаль хезмәтнең баш вазыйфалары** | |
| Идарә башлыгы; | 01-2-17 |
| мөстәкыйль бүлек башлыгы (мөдире); | 01-2-18 |
| башка структур бүлекчә җитәкчесе. | 01-2-19 |
| **3. Муниципаль хезмәтнең әйдәп баручы вазыйфалары** | |
| Идарә башлыгы урынбасары; | 01-3-20 |
| мөстәкыйль бүлек башлыгы (мөдире) урынбасары; | 01-3-21 |
| башка структур бүлекчә җитәкчесе урынбасары; | 01-3-22 |
| мөстәкыйль бүлек мөдире; | 01-3-23 |
| башкарма комитет җитәкчесе ярдәмчесе; | 01-3-24 |
| башкарма комитет җитәкчесе киңәшчесе; | 01-3-25 |
| идарә составындагы бүлек башлыгы; | 01-3-26 |

идарә составындагы сектор мөдире; 01-3-27
мөстәкыйль бүлек составындагы сектор мөдире. 01-3-28

4. Муниципаль хезмәтнең өлкән вазыйфалары

Идарәнең, бүлекнең, секторның, башка структур бүлекчәнең баш белгече; 01-4-29
идарәнең, бүлекнең, секторның, башка структур бүлекчәнең әйдәп баручы белгече. 01-4-30

5. Муниципаль хезмәтнең кече вазыйфалары

Идарәнең, бүлекнең, секторның, башка структур бүлекчәнең 1 категорияле белгече; 01-5-31
идарәнең, бүлекнең, секторның, башка структур бүлекчәнең 2 категорияле белгече; 01-5-32
идарә, бүлек, сектор, башка структур бүлекчә белгече. 01-5-33

## 3 бүлек. ҖИРЛЕ ҮЗИДАРӘНЕҢ БАШКА ОРГАНЫНДАГЫ, ҖИРЛЕ ҮЗИДАРӘНЕҢ БАШКА ОРГАНЫ АППАРАТЫНДАГЫ МУНИЦИПАЛЬ ХЕЗМӘТ ВАЗЫЙФАЛАРЫ

1. Муниципаль хезмәтнең югары вазыйфалары

Җирле үзидарәнең башка органы җитәкчесе; 01-1-34
җирле үзидарәнең башка органы җитәкчесе урынбасары. 01-1-35

2. Муниципаль хезмәтнең баш вазыйфалары

Мөстәкыйль бүлек башлыгы (мөдире); 01-2-36

3. Муниципаль хезмәтнең әйдәп баручы вазыйфалары

Мөстәкыйль бүлек башлыгы (мөдире) урынбасары; 01-3-37
мөстәкыйль бүлек мөдире; 01-3-38
мөстәкыйль бүлек составындагы сектор мөдире; 01-3-39
контроль-исәпләү органы аппатарының баш инспекторы. 01-3-40

4. Муниципаль хезмәтнең өлкән вазыйфалары

Бүлекнең, секторның баш белгече; 01-4-41
вүлекнең, секторның әйдәп баручы белгече; 01-4-42
контроль-исәпләү органы аппатарының әйдәп баручы инспекторы. 01-4-43

5. Муниципаль хезмәтнең кече вазыйфалары

Бүлекнең, секторның 1 категорияле белгече; 01-5-44
бүлекнең, секторның 2 категорияле белгече; 01-5-46
бүлек, сектор белгече; 01-5-47
контроль-исәпләү органы аппатары инспекторы. 01-5-48

## II кисәк

## ШӘҺӘР ОКРУГЫНДАГЫ МУНИЦИПАЛЬ ХЕЗМӘТ ВАЗЫЙФАЛАРЫ

## 4 бүлек. ВӘКИЛЛЕКЛЕ ОРГАН АППАРАТЫНДАГЫ МУНИЦИПАЛЬ ХЕЗМӘТ ВАЗЫЙФАЛАРЫ

| | |
|---|---|
| **1. Муниципаль хезмәтнең югары вазыйфалары** | |
| Аппарат җитәкчесе; | 02-1-01 |
| эшләр идарәчесе. | 02-1-02 |
| **2. Муниципаль хезмәтнең баш вазыйфалары** | |
| Идарә башлыгы; | 02-2-03 |
| идарә башлыгының беренче урынбасары; | 02-2-04 |
| идарә башлыгы урынбасары; | 02-2-05 |
| мөстәкыйль бүлек башлыгы (мөдире); | 02-2-06 |
| башка структур бүлекчә җитәкчесе; | 02-2-07 |
| мөстәкыйль бүлек башлыгы (мөдире) урынбасары. | 02-2-08 |
| **3. Муниципаль хезмәтнең әйдәп баручы вазыйфалары** | |
| Шәһәр округы башлыгы ярдәмчесе; | 02-3-09 |
| шәһәр округы башлыгы киңәшчесе. | 02-3-10 |
| **4. Муниципаль хезмәтнең өлкән вазыйфалары** | |
| Идарәнең, бүлекнең, башка структур бүлекчәнең баш белгече; | 02-4-11 |
| идарәнең, бүлекнең, башка структур бүлекчәнең әйдәп баручы белгече. | 02-4-12 |
| **5. Муниципаль хезмәтнең кече вазыйфалары** | |
| Идарәнең, бүлекнең, башка структур бүлекчәнең 1 категорияле белгече; | 02-5-13 |
| идарәнең, бүлекнең, башка структур бүлекчәнең 2 категорияле белгече; | 02-5-14 |
| идарә, бүлек, башка структур бүлекчә белгече. | 02-5-15 |

## 5 бүлек. БАШКАРМА КОМИТЕТТАГЫ, БАШКАРМА КОМИТЕТ АППАРАТЫНДАГЫ МУНИЦИПАЛЬ ХЕЗМӘТ ВАЗЫЙФАЛАРЫ

| | |
|---|---|
| **1. Муниципаль хезмәтнең югары вазыйфалары** | |
| Башкарма комитет җитәкчесе; | 02-1-16 |
| башкарма комитет җитәкчесенең беренче урынбасары; | 02-1-17 |
| башкарма комитет җитәкчесе урынбасары; | 02-1-18 |
| башкарма комитет аппараты җитәкчесе; | 02-1-19 |
| район администрациясе башкарма комитеты башлыгы; | 02-1-20 |
| башкарма комитет территориясе префекты; | 02-1-21 |
| башкарма комитетның эшләр идарәчесе; | 02-1-22 |
| башкарма комитет аппараты җитәкчесе урынбасары; | 02-1-23 |
| башкарма комитетның эшләр идарәчесе урынбасары. | 02-1-24 |

2. Муниципаль хезмәтнең баш вазыйфалары

| | |
|---|---|
| Идарә башлыгы; | 02-2-25 |
| башка структур бүлекчә җитәкчесе; | 02-2-26 |
| район администрациясе башкарма комитеты башлыгының беренче урынбасары; | 02-2-27 |
| идарә башлыгының беренче урынбасары; | 02-2-28 |
| башка структур бүлекчә җитәкчесенең беренче урынбасары; | 02-2-29 |
| идарә башлыгы урынбасары; | 02-2-30 |
| башка структур бүлекчә җитәкчесе урынбасары; | 02-2-31 |
| район администрациясе башкарма комитеты башлыгы урынбасары; | 02-2-32 |
| мөстәкыйль бүлек башлыгы (мөдире); | 02-2-33 |
| район администрациясе башкарма комитеты аппараты җитәкчесе; | 02-2-34 |
| мөстәкыйль бүлек башлыгы (мөдире) урынбасары. | 02-2-35 |

3. Муниципаль хезмәтнең әйдәп баручы вазыйфалары

| | |
|---|---|
| Мөстәкыйль бүлек мөдире; | 02-3-36 |
| башкарма комитет җитәкчесе ярдәмчесе; | 02-3-37 |
| башкарма комитет җитәкчесе киңәшчесе; | 02-3-38 |
| идарә составындагы бүлек, башка структур бүлекчә башлыгы; | 02-3-39 |
| идарә составындагы бүлек, башка структур бүлекчә башлыгы урынбасары; | 02-3-40 |
| район администрациясе башкарма комитеты бүлеге башлыгы; | 02-3-41 |
| идарә составындагы сектор, башка структур бүлекчә мөдире; | 02-3-42 |
| мөстәкыйль бүлек составындагы сектор мөдире; | 02-3-43 |
| район администрациясе башкарма комитеты бүлеге башлыгы урынбасары. | 02-3-44 |

4. Муниципаль хезмәтнең өлкән вазыйфалары

| | |
|---|---|
| Идарәнең, бүлекнең, секторның, башка структур бүлекчәнең баш белгече; | 02-4-45 |
| идарәнең, бүлекнең, секторның, башка структур бүлекчәнең әйдәп баручы белгече. | 02-4-46 |

5. Муниципаль хезмәтнең кече вазыйфалары

| | |
|---|---|
| Идарәнең, бүлекнең, секторның, башка структур бүлекчәнең 1 категорияле белгече; | 02-5-47 |
| идарәнең, бүлекнең, секторның, башка структур бүлекчәнең 2 категорияле белгече; | 02-5-48 |
| идарә, бүлек, сектор, башка структур бүлекчә белгече. | 02-5-49 |

## 6 бүлек. ҖИРЛЕ ҮЗИДАРӘНЕҢ БАШКА ОРГАНЫНДАГЫ, ҖИРЛЕ ҮЗИДАРӘНЕҢ БАШКА ОРГАНЫ АППАРАТЫНДАГЫ МУНИЦИПАЛЬ ХЕЗМӘТ ВАЗЫЙФАЛАРЫ

| | |
|---|---|
| **1. Муниципаль хезмәтнең югары вазыйфалары** | |
| Җирле үзидарәнең башка органы җитәкчесе; | 02-1-50 |
| җирле үзидарәнең башка органы җитәкчесенең беренче урынбасары; | 02-1-51 |
| җирле үзидарәнең башка органы җитәкчесе урынбасары. | 02-1-52 |
| **2. Муниципаль хезмәтнең баш вазыйфалары** | |
| Идарә башлыгы; | 02-2-53 |
| идарә башлыгы урынбасары; | 02-2-54 |
| мөстәкыйль бүлек башлыгы (мөдире); | 02-2-55 |
| мөстәкыйль бүлек башлыгы (мөдире) урынбасары; | 02-2-56 |
| **3. Муниципаль хезмәтнең әйдәп баручы вазыйфалары** | |
| Мөстәкыйль сектор мөдире; | 02-3-57 |
| идарә составындагы бүлек башлыгы; | 02-3-58 |
| идарә составындагы сектор мөдире; | 02-3-59 |
| мөстәкыйль бүлек составындагы сектор мөдире; | 02-3-60 |
| контроль-исәпләү органы аппатарының баш инспекторы. | 02-3-61 |
| **4. Муниципаль хезмәтнең өлкән вазыйфалары** | |
| Идарәнең, бүлекнең, секторның баш белгече; | 02-4-62 |
| Идарәнең, бүлекнең, секторның әйдәп баручы белгече; | 02-4-63 |
| Контроль-исәпләү органы аппаратының әйдәп баручы инспекторы. | 02-4-64 |
| **5.Муниципаль хезмәтнең кече вазыйфалары** | |
| Идарәнең, бүлекнең, секторның 1 категорияле белгече; | 02-5-65 |
| идарәнең, бүлекнең, секторның 2 категорияле белгече; | 02-5-66 |
| идарә, бүлек, сектор белгече; | 02-5-67 |
| контроль-исәпләү органы аппатары инспекторы. | 02-5-68 |

## III кисәк

## РЕСПУБЛИКА ӘҺӘМИЯТЕНДӘГЕ ШӘҺӘР НИГЕЗЕНДӘ ТӨЗЕЛГӘН ШӘҺӘР ҖИРЛЕГЕНДӘГЕ МУНИЦИПАЛЬ ХЕЗМӘТ ВАЗЫЙФАЛАРЫ

## 7 бүлек. ВӘКИЛЛЕКЛЕ ОРГАН АППАРАТЫНДАГЫ МУНИЦИПАЛЬ ХЕЗМӘТ ВАЗЫЙФАЛАРЫ

1. Муниципаль хезмәтнең югары вазыйфалары

| | |
|---|---|
| Аппарат башлыгы (эшләр идарәчесе). | 03-1-01 |

2. Муниципаль хезмәтнең баш вазыйфалары

| | |
|---|---|
| Мөстәкыйль бүлек башлыгы (мөдире). | 03-2-02 |

3. Муниципаль хезмәтнең әйдәп баручы вазыйфалары

| | |
|---|---|
| мөстәкыйль бүлек башлыгы (мөдире) урынбасары; | 03-3-03 |
| шәһәр җирлеге башлыгы ярдәмчесе; | 03-3-04 |
| шәһәр җирлеге башлыгы киңәшчесе. | 03-3-05 |

4. Муниципаль хезмәтнең өлкән вазыйфалары

| | |
|---|---|
| Бүлекнең баш белгече; | 03-4-06 |
| бүлекнең әйдәп баручы белгече. | 03-4-07 |

5. Муниципаль хезмәтнең кече вазыйфалары

| | |
|---|---|
| бүлекнең 1 категорияле белгече; | 03-5-08 |
| бүлекнең 2 категорияле белгече; | 03-5-09 |
| бүлек белгече. | 03-5-10 |

## 8 бүлек. БАШКАРМА КОМИТЕТТАГЫ, БАШКАРМА КОМИТЕТ АППАРАТЫНДАГЫ МУНИЦИПАЛЬ ХЕЗМӘТ ВАЗЫЙФАЛАРЫ

1. Муниципаль хезмәтнең югары вазыйфалары

| | |
|---|---|
| Башкарма комитет җитәкчесе; | 03-1-11 |
| башкарма комитет җитәкчесе урынбасары. | 03-1-12 |

2. Муниципаль хезмәтнең баш вазыйфалары

| | |
|---|---|
| Башкарма комитет аппараты җитәкчесе (эшләр идарәчесе); | 03-2-13 |
| идарә башлыгы; | 03-2-14 |
| мөстәкыйль бүлек башлыгы (мөдире); | 03-2-15 |
| башка структур бүлекчә җитәкчесе. | 03-2-16 |

3. Муниципаль хезмәтнең әйдәп баручы вазыйфалары

| | |
|---|---|
| Идарә башлыгы урынбасары; | 03-3-17 |
| мөстәкыйль бүлек башлыгы (мөдире) урынбасары; | 03-3-18 |
| башка структур бүлекчә җитәкчесе урынбасары; | 03-3-19 |
| мөстәкыйль сектор мөдире; | 03-3-20 |
| башкарма комитет җитәкчесе ярдәмчесе; | 03-3-21 |
| башкарма комитет җитәкчесе киңәшчесе; | 03-3-22 |
| идарә составындагы бүлек башлыгы; | 03-3-23 |
| идарә составындагы сектор мөдире; | 03-3-24 |
| мөстәкыйль бүлек составындагы сектор мөдире. | 03-3-25 |

4. Муниципаль хезмәтнең өлкән вазыйфалары

| | |
|---|---|
| Идарәнең, бүлекнең, секторның, башка структур бүлекчәнең баш белгече; | 03-4-26 |
| идарәнең, бүлекнең, секторның, башка структур бүлекчәнең әйдәп баручы белгече; | 03-4-27 |

5. Муниципаль хезмәтнең кече вазыйфалары

| | |
|---|---|
| Идарәнең, бүлекнең, секторның, башка структур бүлекчәнең 1 категорияле белгече; | 03-5-28 |

Идарәнең, бүлекнең, секторның,
башка структур бүлекчәнең 2 категорияле белгече; 03-5-29
Идарә, бүлек, сектор,
башка структур бүлекчә белгече. 03-5-30

## 9 бүлек. ҖИРЛЕ ҮЗИДАРӘНЕҢ БАШКА ОРГАНЫНДАГЫ, ҖИРЛЕ ҮЗИДАРӘНЕҢ БАШКА ОРГАНЫ АППАРАТЫНДАГЫ МУНИЦИПАЛЬ ХЕЗМӘТ ВАЗЫЙФАЛАРЫ

1. Муниципаль хезмәтнең югары вазыйфалары

Җирле үзидарәнең башка органы җитәкчесе; 03-1-31
җирле үзидарәнең башка органы җитәкчесе урынбасары. 03-1-32

2. Муниципаль хезмәтнең баш вазыйфалары

Мөстәкыйль бүлек башлыгы (мөдире). 03-2-33

3. Муниципаль хезмәтнең әйдәп баручы вазыйфалары

Мөстәкыйль бүлек башлыгы (мөдире) урынбасары; 03-3-34
мөстәкыйль сектор мөдире; 03-3-35
мөстәкыйль бүлек составындагы сектор мөдире. 03-3-36

4. Муниципаль хезмәтнең өлкән вазыйфалары

бүлекнең, секторның әйдәп баручы белгече. 03-4-37

5. Муниципаль хезмәтнең кече вазыйфалары

бүлекнең, секторның 1 категорияле белгече; 03-5-38
бүлекнең, секторның 2 категорияле белгече; 03-5-39
бүлек, сектор белгече. 03-5-40

## IV кисәк

## РАЙОН ӘҺӘМИЯТЕНДӘГЕ ШӘҺӘР НИГЕЗЕНДӘ ТӨЗЕЛГӘН ШӘҺӘР ҖИРЛЕГЕНДӘГЕ МУНИЦИПАЛЬ ХЕЗМӘТ ВАЗЫЙФАЛАРЫ

## 10 бүлек. ВӘКИЛЛЕКЛЕ ОРГАН АППАРАТЫНДАГЫ МУНИЦИПАЛЬ ХЕЗМӘТ ВАЗЫЙФАЛАРЫ

1. Муниципаль хезмәтнең югары вазыйфалары

Аппарат җитәкчесе (эшләр идарәчесе). 04-1-01

2. Муниципаль хезмәтнең баш вазыйфалары

Мөстәкыйль бүлек башлыгы (мөдире). 04-1-02

3. Муниципаль хезмәтнең әйдәп баручы вазыйфалары

Мөстәкыйль бүлек башлыгы (мөдире) урынбасары. 04-3-03

4. Муниципаль хезмәтнең өлкән вазыйфалары

Баш белгеч; 04-4-04
Әйдәп баручы белгеч 04-4-05

5. Муниципаль хезмәтнең кече вазыйфалары

1 категорияле белгеч; 04-5-06

| | |
|---|---|
| 2 категорияле белгеч; | 04-5-07 |
| белгеч. | 04-5-08 |

## 11 бүлек. БАШКАРМА КОМИТЕТТАГЫ, БАШКАРМА КОМИТЕТ АППАРАТЫНДАГЫ МУНИЦИПАЛЬ ХЕЗМӘТ ВАЗЫЙФАЛАРЫ

| | |
|---|---|
| **1. Муниципаль хезмәтнең югары вазыйфалары** | |
| Башкарма комитет җитәкчесе; | 04-1-09 |
| башкарма комитет җитәкчесе урынбасары. | 04-1-10 |
| **2. Муниципаль хезмәтнең баш вазыйфалары** | |
| Башкарма комитет аппараты җитәкчесе (эшләр идарәчесе); | 04-2-11 |
| мөстәкыйль бүлек башлыгы (мөдире); | 04-2-12 |
| башка структур бүлекчә җитәкчесе. | 04-2-13 |
| **3. Муниципаль хезмәтнең әйдәп баручы вазыйфалары** | |
| мөстәкыйль бүлек башлыгы (мөдире) урынбасары; | 04-3-14 |
| башка структур бүлекчә җитәкчесе урынбасары. | 04-3-15 |
| **4. Муниципаль хезмәтнең өлкән вазыйфалары** | |
| бүлекнең, башка структур бүлекчәнең баш белгече; | 04-4-16 |
| бүлекнең, башка структур бүлекчәнең әйдәп баручы белгече. | 04-4-17 |
| **5. Муниципаль хезмәтнең кече вазыйфалары** | |
| бүлекнең, башка структур бүлекчәнең 1 категорияле белгече; | 04-5-18 |
| бүлекнең, башка структур бүлекчәнең 2 категорияле белгече; | 04-5-19 |
| бүлек, башка структур бүлекчә белгече. | 04-5-20 |

## 12 бүлек. ҖИРЛЕ ҮЗИДАРӘНЕҢ БАШКА ОРГАНЫНДАГЫ, ҖИРЛЕ ҮЗИДАРӘНЕҢ БАШКА ОРГАНЫ АППАРАТЫНДАГЫ МУНИЦИПАЛЬ ХЕЗМӘТ ВАЗЫЙФАЛАРЫ

| | |
|---|---|
| **Муниципаль хезмәтнең югары вазыйфалары** | |
| Җирле үзидарәнең башка органы җитәкчесе; | 04-1-21 |
| җирле үзидарәнең башка органы җитәкчесе урынбасары. | 04-1-22 |
| **2. Муниципаль хезмәтнең баш вазыйфалары** | |
| Мөстәкыйль бүлек башлыгы (мөдире). | 04-2-23 |
| **3. Муниципаль хезмәтнең әйдәп баручы вазыйфалары** | |
| Мөстәкыйль бүлек башлыгы (мөдире) урынбасары. | 04-3-24 |
| **4. Муниципаль хезмәтнең өлкән вазыйфалары** | |
| Әйдәп баручы белгеч. | 04-4-25 |
| **5. Муниципаль хезмәтнең кече вазыйфалары** | |
| 1 категорияле белгеч; | 04-5-26 |

| | |
|---|---|
| 2 категорияле белгеч; | 04-5-27 |
| белгеч. | 04-5-28 |

V кисәк

## ШӘҺӘР ТИБЫНДАГЫ ПОСЕЛОК НИГЕЗЕНДӘ ТӨЗЕЛГӘН ШӘҺӘР ҖИРЛЕГЕНДӘГЕ МУНИЦИПАЛЬ ХЕЗМӘТ ВАЗЫЙФАЛАРЫ

### 13 бүлек. ВӘКИЛЛЕКЛЕ ОРГАН АППАРАТЫНДАГЫ МУНИЦИПАЛЬ ХЕЗМӘТ ВАЗЫЙФАЛАРЫ

1. Муниципаль хезмәтнең баш вазыйфалары

| | |
|---|---|
| Мөстәкыйль бүлек башлыгы (мөдире). | 05-2-01 |

2. Муниципаль хезмәтнең өлкән вазыйфалары

| | |
|---|---|
| Әйдәп баручы белгеч. | 05-4-02 |

3. Муниципаль хезмәтнең кече вазыйфалары

| | |
|---|---|
| 1 категорияле белгеч; | 05-5-03 |
| 2 категорияле белгеч; | 05-5-04 |
| белгеч. | 05-5-05 |

### 14 бүлек. БАШКАРМА КОМИТЕТТАГЫ, БАШКАРМА КОМИТЕТ АППАРАТЫНДАГЫ МУНИЦИПАЛЬ ХЕЗМӘТ ВАЗЫЙФАЛАРЫ

1. Муниципаль хезмәтнең югары вазыйфалары

| | |
|---|---|
| башкарма комитет җитәкчесе; | 05-1-06 |
| башкарма комитет җитәкчесе урынбасары. | 05-1-07 |

2. Муниципаль хезмәтнең баш вазыйфалары

| | |
|---|---|
| Мөстәкыйль бүлек башлыгы (мөдире). | 05-2-08 |

3. Муниципаль хезмәтнең өлкән вазыйфалары

| | |
|---|---|
| Әйдәп баручы белгеч. | 05-4-09 |

4. Муниципаль хезмәтнең кече вазыйфалары

| | |
|---|---|
| 1 категорияле белгеч; | 05-5-10 |
| 2 категорияле белгеч; | 05-5-11 |
| белгеч. | 05-5-12 |

### 15 бүлек. ҖИРЛЕ ҮЗИДАРӘНЕҢ БАШКА ОРГАНЫНДАГЫ, ҖИРЛЕ ҮЗИДАРӘНЕҢ БАШКА ОРГАНЫ АППАРАТЫНДАГЫ МУНИЦИПАЛЬ ХЕЗМӘТ ВАЗЫЙФАЛАРЫ

1. Муниципаль хезмәтнең югары вазыйфалары

| | |
|---|---|
| Җирле үзидарәнең башка органы җитәкчесе; | 05-1-13 |
| җирле үзидарәнең башка органы җитәкчесе урынбасары; | 05-1-14 |

2. Муниципаль хезмәтнең баш вазыйфалары

Мөстәкыйль бүлек башлыгы (мөдире). 05-2-15

3. Муниципаль хезмәтнең өлкән вазыйфалары

Әйдәп баручы белгеч. 05-4-16

4. Муниципаль хезмәтнең кече вазыйфалары

1 категорияле белгеч; 05-5-17
2 категорияле белгеч; 05-5-18
белгеч. 05-5-19

VI кисәк

## АВЫЛ ҖИРЛЕГЕНДӘГЕ МУНИЦИПАЛЬ ХЕЗМӘТ ВАЗЫЙФАЛАРЫ

### 16 бүлек. ВӘКИЛЛЕКЛЕ ОРГАН АППАРАТЫНДАГЫ МУНИЦИПАЛЬ ХЕЗМӘТ ВАЗЫЙФАЛАРЫ

1. Муниципаль хезмәтнең өлкән вазыйфалары

әйдәп баручы белгеч. 06-4-01

2. Муниципаль хезмәтнең кече вазыйфалары

1 категорияле белгеч; 06-5-02
2 категорияле белгеч; 06-5-03
белгеч. 06-5-04

### 17 бүлек. БАШКАРМА КОМИТЕТ АППАРАТЫНДАГЫ МУНИЦИПАЛЬ ХЕЗМӘТ ВАЗЫЙФАЛАРЫ

1. Муниципаль хезмәтнең югары вазыйфалары

башкарма комитет җитәкчесе; 06-1-05
башкарма комитет җитәкчесе урынбасары (секретарь). 06-1-06

2. Муниципаль хезмәтнең өлкән вазыйфалары

әйдәп баручы белгеч. 06-4-07

3. Муниципаль хезмәтнең кече вазыйфалары

1 категорияле белгеч; 06-5-08
2 категорияле белгеч; 06-5-09
белгеч. 06-5-10

<*> Татарстан Республикасы муниципаль хезмәте вазыйфасының теркәү номерында беренче ике сан бүлекнең тәртип номерына туры килә, өченчесе - вазыйфа категориясенә (югары – 1, баш – 2, әйдәп баручы – 3, өлкән – 4, кече – 5), дүртенчесе һәм бишенчесе – вазыйфаның бүлектә тәртип номерына туры килә.».

**5 статья**

1. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көннән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

2. Әлеге Закон үз көченә кергән көнгә кадәр билгеләнгән тиешле еллар эшләгән өчен пенсияләр, пенсиягә өстәмә түләүләр күләме, әлеге Закон нигезләмәләрен исәпкә алып, әлеге Закон үз көченә кергән көннән яңадан исәпләнергә тиеш. Әгәр тиешле еллар эшләгән өчен пенсияләр, пенсиягә өстәмә түләүләр күләме әлеге Закон нигезендә элек билгеләнгәннәр белән чагыштырганда кимрәк булган очракта, алар элеккеге күләмдә түләнә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законына**
**АҢЛАТМА**

«Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы закон проекты (алга таба – закон проекты) Татарстан Республикасында дәүләт хезмәтенең һәм муниципаль хезмәтнең имиджын үстерү, югары квалификацияле белгечләрне шул исәптән пенсия белән тәэмин ителешне арттыру юлы белән дә җәлеп итүне һәм тотып калуны стимуллаштыру максатларында эшләнгән.

2024 елның 1 июнендә тиешле еллар эшләгән өчен пенсияләрнең һәм пенсиягә өстәмә түләүләрнең уртача күләме 10 327,34 сум тәшкил итә һәм стажга һәм акчалата тәэмин ителешкә бәйле.

Дәүләт хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләрне башкаручыларга пенсия билгеләү өчен күпчелек очракта тиешле вазыйфаны бер ел башкару җитә.

Моннан тыш, дәүләт хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләрне башкаручыларны акчалата тәэмин итү вазыйфаны биләү дәвамлылыгын исәпкә алмыйча, соңгы хезмәт урыны буенча билгеләнә.

Закон проектында тәкъдим ителгән үзгәрешләр пенсия белән тәэмин ителеш мәсьәләләрен көйләүдә дисбалансны бетерүгә юнәлдерелгән һәм түбәндәгеләрне күздә тота:

дәүләт хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләрне биләгән затлар өчен вазыйфаны башкаруның дәвамлылыгы тиешле норматив хокукый актлар белән билгеләнгән (бүгенге көндә – бер ел) тулы бер срогыннан да ким булмаган вакыт биләү турында таләпләр билгеләүне;

дәүләт хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләрне биләүчеләр өчен пенсияләрне исәпләү өчен акчалата тәэмин ителешне алар биләгән вазыйфа буенча кимендә биш ел (бүгенге көндә мондый минималь чор билгеләнмәгән) дип билгеләүне;

дәүләт хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләрне биләүчеләр өчен пенсиянең минималь күләмен аларның айлык акчалата тәэмин ителешенең 35 проценты күләмендә (бүгенге көндә – 20 процент) билгеләүне.

Татарстан Республикасының түбәндәге законнарына тиешле үзгәрешләр кертелә:

«Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы;

«Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфалары турында» 2006 елның 4 мартындагы 16-ТРЗ номерлы;

«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты, җирле үзидарәнең сайлап куелган органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайлап куелган вазыйфаи заты вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында» 2009 елның 12 февралендәге 15-ТРЗ номерлы;

Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы.

**«Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәрешләр кертелергә яки кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары**

**ИСЕМЛЕГЕ**

«Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актларын үз көчләрен югалткан дип тануны, туктатып торуны, үзгәрешләр кертүне яки кабул итүне таләп итми.

**«Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында»**
**Татарстан Республикасы законы проектын**
**ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

2024 елның 1 мартына 8345 кеше тиешле еллар эшләгән өчен пенсия алучылар, пенсиягә өстәмә түләүләр алучылар булып торалар, шулардан:

2015 кеше (24 процент) – дәүләт һәм муниципаль вазыйфалар биләүчеләр;

6330 кеше (76 процент) – дәүләт хезмәткәрләре һәм муниципаль хезмәткәрләр.

Тиешле еллар эшләгән өчен пенсияләр, пенсиягә өстәмә түләүләр бирү өчен кирәкле акчалар ел саен Татарстан Республикасы бюджетында карала һәм елына 1,0 млрд сум тәшкил итә.

«Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Законы кабул ителүгә бәйле рәвештә 2024 елга Татарстан Республикасы бюджеты акчаларына өстәмә ихтыяҗ күләме 371,7 млн сум тирәсе тәшкил итәчәк.